ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИСКЕ-КАЗАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Куркачи, ул. Клубная, 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык авылы, Клуб ур., 4

тел./факс 8(84365) 70-7-00, e-mail: Ikaz.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**09 июнь, 2021 ел** **№ 13**

**Башкарма комитетның 2021 елның 19 февралендәге 3 номерлы карары белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законнар нигезендә, «Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Иске-Казан авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 19 февралендәге 3 номерлы карары белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5 пунктның 2 нче графасын түбәндәге эчтәлектәге 5 һәм 6 пунктчалар белән тулыландырырга:

«5) йорт китабын саклау бурычы 2017 елның 31 декабренә кадәр торак урыннар милекчеләренә йөкләнгән очракта, мөрәҗәгать итүче итеп йорт китабы күрсәтелә;

6) индивидуаль торак йортка хокук билгеле торган документлар (әгәр милек хокукы күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса) - хуҗалык кенәгәсеннән өземтә өчен.»;

2) 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына буйсынулы оешмалар карамагында булган мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы башка муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>1. Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә. | |

| | | |
|---|---|---|
| формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документларны үз карамагында торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә башка оешмалар | | |

.»;

3) 2.8 пунктның 2 нче графасын түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча белән тулыландырырга:

«2) Башкарма комитет карамагында гражданны яшәү (тору) урыны буенча теркәүне раслаучы белешмәләр булмау.»;

4) 2.15 һәм 2.16 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркемгә мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә) муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, җирле үзидарәнең башкарма күрсәтмә органы органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә, мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәтләрне 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган күпфункцияле үзәкләрдә (комплекслы сорату) берничә дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату юлы белән муниципаль хезмәтне алу мөмкинлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>документлар кабул итү, бирү алып барыла торган бина җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашкан булуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннар булу;<br>мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәтләр алуда тоткарлыкларны узарга ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләргә документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары бозылу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата корректлы булмаган, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Аралашу озынлыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче | |

| | | |
|---|---|---|
| | тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында, КФҮдә алынырга мөмкин. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба - КФҮ) аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең читтән торып эшләү урыннары гамәлгә ашырылмый.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы сорату составында муниципаль хезмәт күрсәтелми | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелсә) һәм электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәткәндә, мөрәҗәгать итүче хокуклы:<br>а) Бердәм порталда яисә Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;<br>б) гаризаны электрон формасын тутыру юлы белән Республика порталының «Шәхси кабинетыннан» файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирергә.<br>Региональ порталның «Шәхси кабинет»ын кулланып муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар җибәрелгәндә, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланыла. Мөрәҗәгать итүче гади электрон имзаны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы карары белән билгеләнгән очракларда кулланырга хокуклы;<br>в) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаларның үтәлеше турында белешмәләр алырга;<br>г) Республика порталы ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;<br>д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;<br>е) Башкарма комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылган карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган муниципаль районның рәсми сайты, Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә шикаять бирергә. | |

.»;

5) 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре»;

6) 3.3.1 пунктта «яисә КФҮ аша» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«5. Муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү**

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Башкарма комитет хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр Башкарма комитетка яисә муниципаль берәмлек Советына шикаять белдерү хокукына ия.

Гариза бирүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы соратуны, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән соратуны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районының муниципаль хокукый актларында тапшырылуы яки башкарылуы каралмаган документларны яисә мәгълүматны тапшыруны яисә гамәлләрне башкаруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, Биектау муниципаль районының муниципаль хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнар, федераль законнар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, Биектау муниципаль районы хокукый актларында кире кагу өчен җирлек булмаган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту.

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткән очракта Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Биектау муниципаль районының муниципаль хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуы;

8) ) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирүнең срогын һәм тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, Биектау муниципаль районының муниципаль хокукый актларында моның өчен нигез булмаса;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр муниципаль хезмәт күрсәткән вакытта кирәкле булган документларны кире какканда аларның юклыгы һәм (яки) тулы булмаганлыгы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматларны таләп итү, яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пунктында каралган очраклардан кала.

5.2. Муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять кәгазь чыганакта яисә электрон рәвештә язмача бирелә.

Шикаятьне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Биектау муниципаль районының рәсми сайтыннан (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып, почта аша җибәрергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеелергә мөмкин.

5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга яки югарырак органга (ул булган очракта) кергән шикаять аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның баш тартуына шикаять биргән очракта, мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул иткәндә яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәткәндә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) гариза бирүчегә җавап бирү өчен гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта), яшәү урыны турында белешмә яисә гариза бирүче - юридик затның исеме, урнашкан урыны турында белешмә, гариза бирүчегә җавап җибәрү өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслары) (ахыргысы булган очракта) һәм почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәткәрнең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән килешмәвенә нигез булган гариза бирүченең дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Мондый очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны тапшырган муниципаль хезмәтне алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу формасында, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән гаризаны кертү вакытында җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү буенча төзәтмәләрне, гариза бирүчегә акчалата чараларны кире кайтару, әгәр акча алу Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә каралмаган булса;

2) шикаятьне канәгатьләндерелүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгәннең икенче көннән үк соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә, теләге булган очракта электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре күрсәтелгән дәлилләнгән җавап хаты җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, әлеге регламентның 5.7 п. күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында Башкарма комитет тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт алу максатларында башкарырга тиешле алга таба гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять җавап белән канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.7 пунктының 2 абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында аргументлы аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

8) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) башкару үзенчәлекләре» дип аталган 6 бүлекне һәм «Читтән торып эшләү урыннары исемлеге һәм документлар кабул итү графигы» дип аталган 3 нче кушымтаны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске-Казан авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.Р.Закирова